ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
N 3

**КАРАР**
11 ноябрь 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге составына керүче Какылы-Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы карарга таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 22 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Какылы-Күл авылы, Елга урамы, 18А йорт адресы буенча урнашкан Какылы-Күл торак пунктының күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан, балаларыннан), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлар тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Какылы-Күл торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (карт агачларны кисү, эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Какылы-Күл торак пунктында җирлек эчендәге юлларны карап тоту (юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү))?»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге башкарма комитетына Какылы-Күл торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат порталында (реер//pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 5 көн дәвамында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы		Ф.Г.Әминова